РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 18 » 11 2022 г. №956

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясындагы 2, 17 өлешләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы, 3, 4 өлешләре, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 25.12.2010 ел, № 98-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы 1 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының15 статьясындагы 3, 5 өлешләре нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 28.04.2020 № 18 карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчасы, 55 статьясындагы 1 пунктының 3 пунктчасына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2021 елның 16 июлендәге 52 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С. П. Самонина